**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СТАРОСЛЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ЭСЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2022 Иске Эсләк авылы № 6

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны Россия Федерациясе законнары белән туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Белешмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең типовой административ регламентын җибәрү турында» 2022 елның 24 февралендәге 04-51/1268 номерлы запросын исәпкә алып, муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.
2. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 01 сентябрендәге 14 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Әхмәтов Д.М.